КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 23 октябрь г.Казань № 912

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар теленә тәрҗемә ителгән уку-укыту-методик комплектларны белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан дәүләт аккреди-тациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча мәгариф программаларын тормышка ашырганда кулланылырга рөхсәт ителгән дәреслекләрнең федераль исемлегенә кертүгә әзерләү чыгымнарын каплау өчен дәүләт аккредитациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча мәгариф программаларын тормышка ашырганда кулланылырга рөхсәт ителә торган уку ярдәмлекләрен бастырып чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар исемлегенә кертелгән оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 23 сентябрь, 906 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 ел, 22 август, 873 нче карарының 4 пункты һәм 6 пунктының бишенче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Адымнар - белемнәргә юл» полилингваль комплекслар өчен укыту-методик комплектлар эшләүгә һәм бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны каплауга юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 24 октябрь, 1133 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 ел, 17 декабрь, 1363 нче карарының 4 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 ел, 2 май, 550 нче карарының 9 һәм 10 пунктлары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин